ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                        КАРАР

01.11.2019          с. Верхний Услон          1119

Югары Ослан муниципаль районының
«Өстәмә белем бирү үзәге»
муниципаль бюджет өстәмә белем бирү
учреждениесенең 2020 елга норматив
чыгымнарын раслау турында»

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге № 273 Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131 - ФЗ Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, «Балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф учреждениеләрен һәм балаларга өстәмә белем бирүче күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 31 декабрендәге №939 карары белән һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комите КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елга кушымталарны расларга:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Балаларга өстәмә белем бирү үзәге» күппрофильле муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесендә өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар әлеге карарга № 1 кушымта нигезендә (алга таба Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Балаларга өстәмә белем бирү үзәге» МББУ);

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының МБУ ДО «ЦДО» өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга 0,5 күләмендә норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициенты.

2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына тәэмин итергә:

- әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнары нигезендә Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Балаларга өстәмә белем бирү үзәге» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесен МБУ ДО «ЦДО» финансларга;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «ЦДО» ДО МБУ әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнарын Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының МБУ ДО «ЦДО»

хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә яңадан карарга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ начальнигына йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе В.С. Тимиряев

Әзерләде:
Касимов В.В.
5 нөсхәдә

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Башкарма комитетының
01.11.2019 ел, № 1119 карарына
№1 кушымта

Югары Ослан муниципаль районының «Өстәмә белем бирү» муниципаль бюджет учреждениесендә өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыру өчен
НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашу | Бер кешегә норматив чыгымнар, елына сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | укуның беренче елы | укуның икенче елы | укуның өченче һәм аннан соң килгән елы |
| Сәнгать-эстетик | авыл җирлеге | 5 970 | 11 055 | 13 266 |
| Физкультура-спорт | авыл җирлеге | 5 868 | 10 867 | 13 041 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 6 273 | 11 617 | 13 940 |
| Туризм һәм туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Экологик-биологик | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Социаль-педагогик | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Социаль-икътисадый | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Табигый-фәнни | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |

Башкарма комитет эшләре белән идарә итүче: А.К. Мингазова